ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү турында» 35-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары С.М. Захарова, О.М. Воронова тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү турында» 35-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2024 елның 23 декабре
№ 159-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
С.М. Захарова,
О.М. Воронова
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү турында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2022 елның 25 июлендәге 46-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 2 өлешенә (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2022, № 57 (I өлеш), «2024» санын «2027» санына алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектына**

# АҢЛАТМА

«Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты (алга таба – закон проекты) авыл җирлегендә яшәүче 65 яшьтән өлкәнрәк затларны медицина оешмаларына илтеп җиткерү өчен «Демография» илкүләм проектының «Өлкән буын» федераль проекты кысаларында Татарстан Республикасының социаль хезмәт күрсәтү оешмалары өчен сатып алынган автотранспорттан (алга таба – махсус автотранспорт) файдалану срогын 2027 елга кадәр (шул елны кертеп) озайту максатларында эшләнде.

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының һәм Россия Федерациясе Хезмәт министрлыгының 2022 елның 6 апрелендәге Махсус автотранспорттан файдалану тәртибе турында методик киңәшләре нигезендә «Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2014 елның 18 декабрендәге 126-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (алга таба – 126-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы) 8 статьяның 8 өлешенә өстәмә пункт кертү өлешендә үзгәреш кертелде, әлеге пункт авыл җирлегендә яшәүчеләрне: 65 яшьтән өлкәнрәк затларны медицина оешмаларына; 65 яшьтән өлкәнрәк затларны һәм инвалидларны – ярымстационар рәвешендә хезмәт күрсәтүче социаль хезмәт күрсәтү оешмаларына махсус автотранспорт белән илтеп җиткерү буенча социаль хезмәт күрсәтүне күздә тота. Аның гамәлдә булу вакыты 2024 елның 31 декабренә кадәр билгеләнгән. Россия Федерациясе Хезмәт министрлыгының 2024 елның 4 декабрендәге 26-1/10/В-21185 номерлы Россия Федерациясе субъектларының иң югары башкарма органнарына җибәрелгән хаты нигезендә, авыл җирлегендә яшәүче 65 яшьтән өлкәнрәк затларны медицина оешмаларына илтеп җиткерү өчен махсус автотранспорттан файдалану срогы 2027 ел (шул елны кертеп) белән чикләнә.

Югарыда бәян ителгәннәрне исәпкә алып, закон проекты белән «Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2022 елның 25 июлендәге 46-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына 126-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 8 өлешенең

7 пунктының гамәлдә булу срогын 2027 елның 31 декабренә кадәр озайтуны күздә тоткан үзгәреш кертү тәкъдим ителә.

Тәкъдим ителә торган үзгәреш Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә акчалар бүлеп бирүне таләп итми, чөнки махсус автотранспортны тотуга (хезмәт күрсәтү, ягулык-майлау материаллары, транспорт йөртүчеләрнең хезмәт хакы) акчалар «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2024 елның 28 ноябрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында 31,3 млн. сум күләмендә каралган.

**«Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү «2022 – 2024 елларда олы яшьтәге гражданнарның аерым категорияләрен һәм инвалидларны медицина оешмаларына һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмаларына илтеп җиткерү буенча ашыгыч социаль хезмәт күрсәтү тәртибен раслау турында» 2022 елның 22 сентябрендәге 1028 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертүне таләп итәчәк.

**«Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү турында»Татарстан Республикасы законы проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми, авыл җирлегендә яшәүче 65 яшьтән өлкәнрәк затларны медицина оешмаларына илтеп җиткерү өчен «Демография» илкүләм проектының «Өлкән буын» федераль проекты кысаларында Татарстан Республикасының социаль хезмәт күрсәтү оешмалары өчен сатып алынган автотранспортны тотуга (хезмәт күрсәтү, ягулык-майлау материаллары, транспорт йөртүчеләрнең хезмәт хакы) акчалар «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2024 елның 28 ноябрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында 31,3 млн. сум күләмендә каралган.